

Татар кешесен тырыш, диләр. Бу чынлап та шулай. Атюрьево районы Тенеш – Татарское Тенишево авылында туып vскән ягымлы, мәрхәмәтле, тырыш һәм булдыклы Римма Исмаил кызы Ингельдеева мона дәлил.
Римма Исмаил кызынын балачагы яшьтәшләреннән аерылмый. Матур табигатьле туган авылы Усть – Рахмановка гомуми урта мәктәбенен беренче сыйныфына укырга килә. Тырыш бала булып vсә ул. Мәктәпкә килгәч тә, торле предметларны тиз vзләштерә, ә математиканы яратырга да олгерә. Усть-Рахмановка мәктәбендә урта белемне алгач, Темников авыл хужалыгы техникумына бухалтер белгечлеген vзләштерегә дип укырга керә. Студент еллары тиз дә, кvнелле дә vтә. Элек авыл хужалыгына ярдәмгә студентларны жибәрә торган иделәр, Римма студентка да курсдашлары белән туган ягы кырларында эшләп алырга туры килә. 1980нче елны, Темниковта техникумны тәмамлап, бухгалтерлык документын кулына алып, Атюрьево районы «Коммунар» колхозы правлениесына эшкә урнаша. Заманында тирә-якка дан тоткан колхоз хезмәткәрләре һәм аларнын унышлары газета, телевидениядә янгырап торды. Яшь белгеч булган Римма Исмаил кызы да белемен, булдыклылыгын тормышка ашырып килде. Тырыш хезмәт нәтижәләре белән раслана; унышларга илтә. Житәкчеләр дә бу бухгалтернын яхшы эшен кvреп, берничә тапкыр Грамоталар белән билгеләделәр. Гомер тиз vтә, шул. Заманалар да гел vзгәреп тора. Колхозлар жимерелгән замана Атюрьево районын да читләтеп vтми, алдынгы «Коммунар» колхозы да тетелә. Шулай Римма Исмаил кызы Ингельдееванын да булгахтерлык карьерасы озелә. Әмма ул югалып калмый, хезмәттә чыныккан эшче Росгосстрахта страховой агент булып китә һәм бvген дә бу олкәдә хормәтле хезмәткәр. Коллегалары аны яраталар, олылыйлар. Биредә дә Хокvмәт бvләкләре унган хезмәткәрнен эш нәтижәләренә дәлил. Юкка гына картлар әйтмәгән, тырыш хезмәт – кешенен канаты.
Бәхетле гомер итә Римма Исмаил кызы. Тормыш иптәше Шәмил Әхмәдулла улы белән бер-берсен анлап, хормәт итеп торалар. Уллары Рамиль һәм кызлары Луизага, тиешле тәрбия биреп, олы юлга чыгарып жибәрәләр. Бvген оныкларын да тәрбияләргә булышалар. Ойләрендә чисталык, похтәлек балкып тора. Бәйрәмнәрдә, тvгәрәк остәл артына жыелган чакта, чәй янына пешерелгән Римма ханымнын милли ашлары – бәлешләре, пәрәмәчләре кvнелләргә рәхәтлек ости.

Еллар vтеп киткәне сизелми генә. 7апрель конне Римма Исмаил кызы 55- яшьлек юбилеен билгеләп vтәр. Юбилее белән якыннары һәм дуслары – яраткан тормыш иптәше, улы һәм кызы тормыш иптәшләре белән, оныклары Тимур, Амаль, Али, Фаилә апасы, Зимфира һәм Фарит гаиләләре белән, Амир һәм Ильмира Ингельдеевлар гаиләләре белән, кvпсанлы якыннары, дуслары, коллегалары котлап изге теләкләрне юллыйлар.
Кадерлебез, син бәхетле: гаилән тигез, инсафлы балаларын.
Кылган гамәлләре белән кабатлыйлар Аналарын. Акыллы да, сабыр да син,
тыйнак һәм итагатьле. Тормыш юлын балкып торсын, нурлы булсын кvнелен. Сәламәт бул, шатлык, бәхет белән бер кайгысыз vтсен гомерен.